*“ТР Кайбыч муниципаль районы ОлыУрсак урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*

# “Фразеологизмнар дөньясында» темасына осталык дәресе

I категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Сафиуллина Зөлфия Кашафетдин кызы

# Максатлары

1. Укучыларны сөйләмдә фразеологизмнарны дөрес кулланырга, сөйләмнән аерып ала белергә өйрәтү.

2 Уйлау, фикерләү, күзаллау сәләтләрен үстерү, тәрҗемә эшен камилләштерү.

3 фразеологизмнарның матур әдәбият әсәрләрендәге урынын билгеләү.

Кыңгырауны ишеттек тә,
Ашыктык без дәрескә,
Җиңнәребезне сызганып,
Тотынабыз зур эшкә.

# Дәреснең девизы:

***Б и т к ү р к е – к ү з,***
***Т е л к ү р к е – с ү з.***

*(Татар халык мәкале)*

**Тел бизәге.**

Сәерсенеп сөйләгәндә,
Төрле сүзләр ычкына.
“Чәчем үрә торды”,- диеп
Шом салам мин еш кына.
Шатлык эчкә сыймас
чакны
Дус-иш, үртәп гел әйтә:
“Күрегезче,күрегезче-
Моның авызы колакта!”

Шаккатканда
шакмакланып
Менә күзем маңгайга
Үчеклиләр шуның өчен
Күтәримме мин гауга?
Мондый сүзләр өчен генә,
Йә,кем мине битәрләр?
Сөйләвеңне сөйкемләүче
Тел бизәге бит алар.

З.Мансур

- Чәчем үрә торды
- шом сала
- шатлык эчкә сыймый
-авызы колакта
-күзе маңгайга менә
- гауга күтәру

- Бу сүзләрне башкача ничек әйтәбез?

-Нинди сүзләрне фразеологизмнар дип атыйбыз?

- Бирелгән сүзләр тезмәсендә кимендә ничә сүз кулланылган?

# Фразеологизмнар.

| Сорау / раслау | Әйе / юк |
|---|---|
| 1 Фразеологизмнардагы сүзләрне башка сүз белән алыштырырга ярыймы?<br><br>2 Фразеологизмнардагы сүзләр арасына башка сүзләр өстәп буламы?<br><br>3 Фразеологизмнарда кимендә ничә сүз булырга тиеш?<br><br>4 Фразеологизм күчерелмә мәгънәне аңлата.<br><br>5 Фразеологизмнарның тәрҗемәсе юк, аларны тәрҗемә итеп булмый. | |

- 1 төркем. Тәрҗемә итәргә.
- Эт белән мәче кебек.
- Ярдәм кулы сузу.
- Сай йөзү.
- Җиңел аяктан.
- Куян кебек куркак.

**Җөя эчендәге сүзләр урынына фразеологизмнарны куярга.**

*1 Бүген дәрестә (көлеп) утыручылар булмады.*

*2 Фәрит бер дә (җавапка аптырамый).*

*3 “Мин татар телен (бик яхшы беләм)”, - диде Алсу.*


*4 Камил (бик тиз генә) кроссвордны чишеп ташлады.*















## Бер кɵнем

Бармакка бармак сукмадым,
Ахры сул аяктан тордым.
Урын-җирне дә җыймыйча,
Мәктәбемә китеп бардым.
Борыным салынган иде,
Очрады, ярый, җан дустым.
Күңел күтәрелде бераз,
“Исәнме!”, дип, кулын кыстым.

Без икәүдән- икәү генә –
Яттан шигырь сɵйләп бардык.
Кɵне буе баш күтәрми,
Җиң сызганып белем алдык.

Судан коры чыктым бүген:
Сорадылар – җавап бирдем.
Сүзгә кесәгә кермичә,
Матур итеп сɵйли белдем.

Тел очында торган җавап,
“Эһ” дигәнче, башка килде.
Сүзне сүзгә ялгый белдем
Алдым шулай яхшы билге.
Башым күккә тия язды,
Борын күтәрмәдем ләкин.
“5”ле алгач, кәеф яхшы,
Ал да гɵлгә әйләнде кɵн.

Очып кына кайттым ɵйгә,
Әниемнең мин уң кулы.
Бɵтен савыт-сабаларны
Ялт иттерде үскән улы!

Шайтан аяк сындырырлык
Иде йокы бүлмәсендә.
Трай тибеп эш чыкмас, дип,
Гɵл иттердем һәммәсен дә

(Г.Әхтәмова)

| Сорау / раслау | Әйе / юк |
|---|---|
| 1 Фразеологизмнардагы сүзләрне башка сүз белән алыштырырга ярыймы? | Әйе |
| 2 Фразеологизмнардагы сүзләр арасына башка сүзләр өстәп буламы? | Юк |
| 3 Фразеологизмнарда кимендә өч сүз булырга тиеш? | Әйе |
| 4 Фразеологизм күчерелмә мәгънәне аңлата. | Әйе |
| 5 Фразеологизмнарның тәрҗемәсе юк, аларны тәрҗемә итеп булмый. | Юк |

# Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!